**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 7 февраль | № 67

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына тапшырылган җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын раслау хакында» 2016 ел, 8 апрель, 200 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-92 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына тапшырылган җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын раслау хакында» 2016 ел, 8 апрель, 200 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча» сүзләрен «муниципаль район составына керә торган шәһәр

җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «җир кишәрлекләре белән эш итү буенча» сүзләрен «җир кишәрлекләрен бирү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

карарның беренче абзацында «җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча» сүзләрен «муниципаль район составына керә торган шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына тапшырылган җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасы исемендә «җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча» сүзләрен «муниципаль район составына керә торган шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\67.doc